# 6 нчы март
# Сыйныф эше

Тема:

# Дәреснең темасы



# Туган көн

# Туган көнгә ничек чакырырга?



- Гафу үтенергә
- Исәнләшергә
- Ягымлы итеп сөйләшергә
- Рәхмәт әйтергә

# Балалар, очрашкач, бер-берсенә нинди сүзләр әйтәләр?



- Исәнмесез!
- Исәнме!
- Туган көнең белән!
- Туган көнең котлы булсын!
- Бәхетле бул!



# "Без чакырдык кунаклар"



Ләйсәннең туган көненә
Без чакырдык кунаклар;
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.
Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән.
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнең сайлап ал.

# Туган көнгә нәрсә бүләк итәргә?






- Үз кулларың белән ясаган әйбер (открытка, гербарий, чиккән кулъяулык).
- Үзең үстергән чәчәкләр.
- Китап.


# Кунакта нинди уеннар уйнап була?

- Шахмат
- Домино
- Шашка
- Мозаика
- Лото
- Йөзек салыш
- Мәкаль әйтеш













# Мин башлыйм, син дәвам ит!

- Кунак булсаң,

тыйнак бул.

- Инә дә бүләк,


дөя дә бүләк.

- Киемгә карап каршы алалар,

акылга карап озаталар.


- Матурлык көлмәк белән сәдәптә түгел,

оят белән әдәптә.



# Бии итек, читекләр

Гармун уйныйм, гармун уйныйм
Һаман гармун уйныйм мин.
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин.
Учларыңны шапылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да,
Тыпыр-тыпыр,тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.
Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин.
Остарып җиткәч барсын да
Биетергә уйлыйм мин.



# Өстәл янында үз-үзеңне ничек тотарга?



**1.Өстәл янында башыңа киеп утырма.**
**2.Өстәл өстенә терсәкләреңне куйма.**
**3.Ашаганда сөйләшмә.**
**4.Тавышсыз ашарга тырыш.**
**5.Ипине зур кабып ашама.**
**6.Пычактан ашама.**
**7.Ерактагы азыкка өстәл аша сузылма, әдәпле генә итеп,алып бирүләрен сора.**
**8.Азыкны сайлап алма.**
**9.Компотның җимеш орлыкларын төкермә.**
**10.Ашаганнан соң, чәнечке белән пычакны тәлинкәгә куй.**
**11.Кашыгыңны чынаяк яки стакан эчендә калдырма.**
**12.Ашаганда укыма.**
**13.Иреннәреңне сөртү өчен кечкенә тастымалдан(салфеткадан)файдалан.**

# "Туган көн" җыры

Бәйрәмнәрне бик яратам,
Матур алар һәрберсе.
Арасында иң яраткан-
Була икән тик берсе.

Җырлыйсым килә бүген,
Биисем килә бүген,
Чөнки,чөнки, чөнки нәкъ-
Бүген бит туган көнем.
Чөнки,чөнки, чөнки нәкъ-
Бүген бит туган көнем.

